ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar. ru

**КАРАР**

**18 июль 2022 ел** **№17**

**Аерым норматив-хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясындагы 1 өлеше, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Советының «Арча муниципаль районы Носы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген туктату турында» 2011 елның 6 декабрендәге 7 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Носы авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Носы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексын раслау турында» 24.02.2011 №1;
- «Носы авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен һәм исемлеген раслау турында» 31.08.2010 №13;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов